**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023елның 27 декабре 4096 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара эшчәнлеге тәртибе турында”**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара эшчәнлеге тәртибе турында” 2019 елның 28 февралендәге 488 номерлы карарга, кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г.Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

*Татарстан РеспубликасыЛаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның __ __ номерлы карарына кушымта*

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара эшчәнлеге тәртибе турында” 2019 елның 28 февралендәге 488 номерлы қарарга үзгәрешләр кертү турында**

**15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары "коммерцияле булмаган оешмалар турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган формаларда ирекле (волонтерлык) эшчәнлеккә ярдәм күрсәтәләр;

1) **кушымтаның 3 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга оештыру, мәгълүмати, методик һәм башка ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче оешмалар, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлектә ярдәм күрсәтү.
Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге түбәндәге максатларда башкарыла:
- гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү һәм яклау максатларында, шул исәптән аз керемлеләрнең матди хәлен яхшырту, үзләренең физик яки интеллектуаль үзенчәлекләре аркасында үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен мөстәкыйль рәвештә тормышка ашыра алмаучы эшсезләрне, инвалидларны һәм башка кешеләрне социаль реабилитацияләү;
- халыкны табигать афәтләре, экологик, сәнәгать яки башка катастрофалар нәтиҗәләрен җиңәргә, бәхетсезлек очракларын булдырмаска әзерләү максатларында;

- гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарны кисәтүдә һәм сүндерүдә, авария-коткару эшләрен үткәрүдә, шулай ук табигать афәтләре, экологик, сәнәгать яки башка катастрофалар, социаль, милли, дини конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргәннәргә, репрессия корбаннарына, качакларга һәм мәҗбүри күченүчеләргә ярдәм күрсәтүдә катнашу;
халыклар арасында тынычлыкны, дуслыкны һәм татулыкны ныгытуга, социаль, милли, дини конфликтларны булдырмауга ярдәм итү;
җәмгыятьтә гаиләнең абруен һәм ролен ныгытуга ярдәм итү;
ана, балачак һәм аталыкны яклауга ярдәм итү;
мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, мәгърифәтчелек, шәхеснең рухи үсеше өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү;

гражданнарның сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның әхлакый-психологик халәтен яхшырту;
физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү (профессиональ спорттан тыш), физик затларның эшләрне түләүсез башкару һәм (яки) хезмәт күрсәтү формасында физкультура һәм спорт чараларын оештыруда һәм (яки) үткәрүдә катнашу;
- әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны саклау;
тарихи, культ, мәдәни яки табигать саклау әһәмияте булган биналарны, объектларны һәм территорияләрне һәм җирләү урыннарын саклау һәм тиешле карап тоту;
халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, караучысыз калган балаларны, авыр тормыш хәлендә булган балаларны социаль реабилитацияләү;
- халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм хокукый белем бирү;
ирекле (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү;
- балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә катнашу;
балалар һәм яшьләрнең фәнни-техник, сәнгать иҗатын үстерүгә ярдәм итү;
балаларны һәм яшьләрне патриотик, рухи-әхлакый тәрбияләүгә ярдәм итү;
иҗтимагый әһәмиятле яшьләр инициативаларына, проектларына, балалар һәм яшьләр хәрәкәтенә, балалар һәм яшьләр оешмаларына ярдәм итү;

социаль реклама җитештерү һәм (яки) тарату буенча эшчәнлеккә ярдәм итү;
гражданнарның социаль куркыныч тәртип формаларын профилактикалауга ярдәм итү;
- хәбәрсез югалган кешеләрне эзләүдә гражданнарның катнашуы;
- медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;
Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итү.